**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 19 март № 165

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләрен шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин итү тәртибен раслау турында» 2004 ел, 16 апрель, 184 нче һәм «Татарстан Республикасы пенсионерларын шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин итү тәртибен раслау турында» 2011 ел, 14 февраль, 97 нче карарларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләрен шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин итү тәртибен раслау турында» 2004 ел, 16 апрель, 184 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 ел, 3 апрель, 146 нчы; 2007 ел, 7 ноябрь, 607 нче; 2009 ел, 30 гыйнвар, 45 нче; 2010 ел, 6 декабрь, 1002 нче; 2014 ел, 8 июль, 472 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

түбәндәге эчтәлекле 4 нче пункт өстәргә:

«4. Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан шифаханә-курорт учреждениеләренә Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләренә шифаханә-курорт дәвалавына юлламалар сатып алуны оештырырга.».

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы пенсионерларын шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин итү тәртибен раслау турында» 2011 ел, 14 февраль, 97 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 11 февраль, 105 нче; 2014 ел, 2 сентябрь, 635 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

түбәндәге эчтәлекле 2 нче пункт өстәргә:

«2. Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан шифаханә-курорт учреждениеләренә Татарстан Республикасы пенсионерларына шифаханә-курорт дәвалавына юлламалар сатып алуны оештырырга.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\165.doc